**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№4 22 ноябрь 2025 ел

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыЮ, тормыш иптәшләре), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юлларга:

- Байлар торак пунктында Тукай урамы, Октябрь урамы буенча урнашкан торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тукай урамындагы юлларны норматив хәлгә китерү (асфальт салу, чокырларны ремонтлау, вак таш салу, төзелеш материаллары сатып алу, ташу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү) ;
- Байлар торак пунктындагы һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (обелиск территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар торак пунктында җирлек юллары эчен карап тоту (юлларны кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Әминова